**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

2021 елның «8» июленнән № 11-89

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 30.10.2017 ел, №30-175 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (№40-229 от 28.08.2018г., №44-257 от 28.12.2018г., №48-281 от 18.04.2019г., №50-303 от 05.07.2019г. №58-357 от 21.02.2020г., №60-373 от 29.04.2020г., №61-380 от 04.06.2020г., №4-29 от 29.12.2020г., №8-61 от 21.04.21 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 9.1 пунктында:

9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

9) яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын – Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә (аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы) катнашучы чит ил гражданлыгын туктату турында, бу хакта муниципаль хезмәткәргә Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит дәүләт гражданлыгы туктатылу турында билгеле булганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә;

түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1) яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә чит ил гражданлыгын алу, чит ил гражданлыгы видын алу, яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булганнан соң, чит ил гражданлыгын алган көннән, яисә яшәүгә рөхсәт алу яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алу турында биш эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә хәбәр итәргә.»;

2) 25.1 пунктының 2 пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда бастырырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (novosheshminsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы

В.М. Козлов